ӘЙДӘ, ХАЛЫККА ХЕЗМӘТКӘ, ХЕЗМӘТ ЭЧЕНДӘ ЙӨЗМӘККӘ!

# САБА ТАҢНАРЫ

19 декабрь
Чәршәмбе,
2018 ел
№92 (10293)

ГАЗЕТА 1930 ЕЛНЫҢ 25 НОЯБРЕННӘН ЧЫГА saba-tannary@tatmedia.com САБИНСКИЕ ЗОРИ saby-rt.ru

**ИГЪТИБАР: КОНКУРС**




## "Яңа елга – "Саба таңнары" белән!"



*Хөрмәтле укучыларыбыз! Яңа ел алдыннан сезнең өчен "Яңа елга – "Саба таңнары" белән!" фотоконкурсында катнашырга чакырабыз. Шарты: 2019 ел өчен район матбугатына язылу, Яңа ел күренеше фонында "Саба таңнары" газетасы белән фотога төшү һәм sabatannar@rambler.ru электрон почтасына җибәрү яки "Вконтакте" социаль челтәренең "Саба таңнары" төркеменә элү (теркәлгән булу кирәк) яки фотоны хат итеп почта аша редакциягә юллау. Конкурс 2019 елның 14 гыйнварына кадәр дәвам итә. Җиңүчеләрне спонсорыбыз "Илфани" кибетенең сертификатлары көтә (1 урын – 3 мең сум, II урын – 2,5 мең сум, III урын – 1,5 мең сум). Башладык!*

**ТЕАТР СӘНГАТЕ БӘЙГЕСЕ**

# «Сәнгатьтә җиңүчене билгеләү кыенрак»

***Узган җомгада районыбыз республиканың яшь театр сөючеләрен кабул итте. Укучылар СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров исемендәге республика балалар театр сәнгате конкурсында инде җиденче тапкыр катнаша һәм быелгысы легендар актерның тууына 90 ел тулган елда үткәрелүе белән дә үзенчәлекле.***

Балаларда театрга мәхәббәт тәрбияләү, Шәүкәт Биктимеровның иҗатын, татар драматургиясен, язучы, артистларын пропагандалау максатыннан үткәрелүче фестивальнең йомгаклау этабында 10 коллектив катнашты.



«Шунысы куанычлы, конкурсның географиясе киңәя бара. Быел бәйгенең беренче этабына 18 районнан 49 коллектив үзенең сәнгати эшен видеоязмада тәкъдим итте. Аларның иң яхшы дип табылганнары йомгаклау турында чыгыш ясау хокукы алды. Быел бәйгегә республиканың иң ерак төбәкләре Мөслим, Буа районнары да кушылды. Бәйгедә районыбызның бөтен мәктәпләре дә диярлек бик актив катнаша», - дип таныштырды Балалар иҗат үзәге директоры, жюри рәисе Венера Хәбибрахманова. Билгеле булганча, конкурс ел саен аерым тематика буенча үткәрелә. Алдагы елларда Шәүкәт Биктимеров уйнаган рольләр, Туфан Миңнуллин әсәрләренә багышланса, быел музыкаль әсәрләргә басым ясалды. Театр бәйгесендә катнашучыларны башкарма комитет аппараты җитәкчесе Марат Кәримов тәбрикләде. «Әлеге конкурс Шәүкәт Биктимеров бакыйлыкка күчкән 2012 елдан бирле узып, ул елдан ел үсә, камилләшә бара. Мин сезнең арада Шәүкәт Биктимеров шикелле легендар артистлар буласына ышанам», – диде Марат Кәримов.

*(Ахыры 2нче биттә).*

# МӨСЛИМӘЛӘР БӘЙГЕ ТОТТЫ

Явлаштау районыбызда дәһшәтле елларда да мәчет манарасын саклап калган бердән-бер авыл. Аллаһ йорты бүгенге көндә дә дин тотучылар өчен игелекле хезмәт итә.Авыл халкы гыйбадәт кылырга, Ислам нигезләрен өйрәнергә бергә эзне суытмый. Мәчеттә инде берничә ел дәвамында Сабадан Рәсимә абыстай Рәхимова хатын-кызларга Коръән укырга, тәҗвид кагыйдәләрен үзләштерергә ярдәм итә. Аның кулы - шәкерте Тәслимә Сабирҗанова белән төрле дини чаралар үткәрүдә дә районыбыз мәхәлләләре арасында башлап йөрүчеләрдән алар. 12 декабрь көнне бирегә Рәсимә абыстай җитәкчелегендә Явлаштау, Иләбәр, Сәрдә, Саба мәчетләрендә дин белемнәрен үзләштерүче ханым-туташлар катнашында «Тарих эзләре буйлап...» дигән кичә узды. Анда мәгърифәтче, аталы татар мөгаллиме, җәмәгать эшлеклесе, «Мөгаллим сәни» дәреслеге авторы Әхмәдһади Максуди, мөгаллимә, Ислам дине белгече, татар кызлары өчен беренче мәдрәсә оештыручы педагог Мөхлисә Бубыйның тормыш юллары бәян ителде. Кичәнең икенче өлеше Саба мөхтәсибәтенең Мөслимәләр берлеге активистлары кулына күчте, 4 мәхәллә хатын-кызларын командаларга бүлеп, дини сораулардан әзерләнгән «Башваткыч» уены үткәрелде. Конкурс барышында ханымнар шулай ук тормышта килеп чыккан төрле вәзгыятьләрдә мөслимә хатын-кыз үзен ничек тотарга тиешлеге, уңган хуҗабикә, акыллы хатын, яраткан килен-каенана булуның «нечкәлекләре» белән дә уртаклаштылар, табын бизәүдә дә осталыкларын күрсәттеләр. Бәйге ахырында һәр катнашучыга район мөхтәсибәте исеменнән истәлек бүләкләре тапшырылды. (**Фотолар *saby-rt.ru* сайтында.**)



*Рәсемдә Рәсимә абыстайга район мөхтәсибәтенең Рәхмәт хаты тапшырылган мизгел.*

**Илмира Галимуллина.**

**КИЧӘ. БҮГЕН. ИРТӘГӘ.**

## Саба – иң яхшы спорт районы

Өченчекөн Казанда 2018 елның иң яхшы спортчыларын бүләкләделәр. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов барлык атлетларга һәм тренерларга республика спортын данлауга зур өлеш керткән өчен рәхмәт белдерде. 2018 ел йомгаклары буенча Саба муниципаль районы быел да "Массакүләм физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт эшенең куелышы буенча иң яхшы авыл районы" номинациясендә җиңүче булды. Дипломны республиканың спорт министры Владимир Леоновтан район башлыгы Рәис Миңнеханов кабул итеп алды. Өч тапкыр рәттән үз титулын саклап калган (2016 елда да җиңүче булган иде) Саба районында физик культура һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүче коллективларга, тренерларга, укытучыларга алдагы елларда да зур уңышлар телибез.(**Фотолар *saby-rt.ru* сайтында.**)

## Түләүсез юридик ярдәм

Россия юристлар ассоциациясенең төбәк бүлеге республиканың Юстиция министрлыгы белән берлектә хокук мәсьәләләре буенча халыкның сорауларын тыңлау максатында мобиль мәгълүмати-консультация төркеме оештырды. Төркемдә Татарстан Президенты, Дәүләт Советы, Конституцион суд аппаратлары һәм төрле министрлыклар белгечләре эшли. Безнең районда халыкка түләүсез юридик ярдәм 20 декабрьдә күрсәтеләчәк. Гражданнарга хокук мәсьәләләрендә консультация бирү Сабада Балалар иҗат үзәге бинасында – 10.00-12.00 сәгатьләрдә, Шәмәрдәндә мәдәният йортында 13.30-15.00 сәгатьләрдә үткәреләчәк.

## Хезмәт сыйфаты кызыксындырса

Саба муниципаль районы башкарма комитеты bus.gov.ru рәсми сайтында социаль өлкә оешмалары (мәгариф, медицина, мәдәният, социаль яклау) тарафыннан күрсәтелүче хезмәтләрнең сыйфаты турында фикер калдырып һәм хезмәт күрсәтүнең сыйфатын, шартларын бәйсез бәяләүнең нәтиҗәләре белән танышып булганлыгы турында хәбәр итә. Моның өчен сайтка http://bus.gov.ru/pub/independentRating/main сылтамасы белән керергә кирәк.

## "Тоннель" операциясе

Сабада атна ахырына таба исерек хәлдә машина йөртүчеләрне һәм штрафны вакытында түләмәүчеләрне ачыклау максатында "Тоннель" операциясе үткәреләчәк.

**АБУНӘ-2019**

*Хөрмәтле газета укучыларыбыз!* 2018 ел төгәлләнүгә таба бара һәм 28 декабрьдә "Саба таңнары"ның быелгы соңгы саны чыгачак. Ә газетаның яңа елда беренче санын 11 гыйнварда кулга алу 25 декабрьгә кадәр беренче чиратта аңа язылырга кирәклеген кабат исегезгә төшерәбез. Гыйнвар башында юбилейларын билгеләп узучы якыннарыгыз һәм туганнарыгызны газета аша котлыйсыгыз килсә, белдерү-реклама бирәсегез булса, 26 декабрьгә кадәр редакциягә килегез.

